**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 8 апрель

№ 199

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт мигрантларын социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән проектларны тормышка ашыручы социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 28 март, 193 нче карары белән расланган Хезмәт мигрантларын социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән проектларны тормышка ашыручы социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт мигрантларын социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән проектларны тормышка ашыручы социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 28 март, 193 нче карары белән расланган Хезмәт мигрантларын социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән проектларны тормышка ашыручы социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле $21^1$ пункт өстәргә:

«$21^1$. Субсидия бирү турында шартнамәләрдә каралган очракларда субсидияләрнең хисап финанс елында файдаланылмаган өлешләре агымдагы финанс елында проектны тормышка ашыру вакыты тәмамланганнан соң 30 көн эчендә, әмма

агымдагы финанс елының 1 декабреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш.»;

22 пунктка пункт «21 пунктның беренче абзацы» сүзләреннән соң «һәм $21^{1}$ пункт» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков